КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 ноябрь

г.Казань

№ 973

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 апрель, 283 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1202 нче; 2021 ел, 19 март, 148 нче; 2022 ел, 18 июль, 686 нчы; 2022 ел, 21 ноябрь, 1244 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 26 июль, 598 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 9 ноябрь, 973 нче
карары редакциясендә)

«Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге»
коммерциягә карамаган автоном оешмасына
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – Үзәк, субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидия Үзәкнең эшләү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.

4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

5. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

хезмәт өчен түләү һәм хезмәткәрләрне матди бүләкләү;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү, бүлмәләрне, җиһаз, җайланмаларны арендалау;

транспорт һәм элемтә хезмәтләрен тәэмин итү;

чаралар үткәрү (укулар, тренинглар, Үзәкнең Иҗтимагый советы утырышлары, түгәрәк өстәлләр);

оештыру техникасын, шәхси компьютерларны, сервер һәм челтәр җиһазларын сатып алу һәм карап тоту;

программа тәэминаты һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итү;

чыгым материаллары сатып алу;

эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнар.

6. Субсидия Үзәккә, әгәр ул субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килә торган айның бересенә түбәндәге таләпләргә туры килсә, бирелә:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләт Оешмасы уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы яки Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (Үзәккә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмый, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, Үзәкнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмый.

7. Субсидия алу өчен Үзәк Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия алуга заявка (алга таба – заявка);

Үзәкнең билгеләнгән тәртиптә таныкланган гамәлгә кую документлары күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча Үзәкнең чыгымнар сметасы;

Үзәкнең җитәкчесе тарафыннан кул куелган әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында белешмә кәгазе (ирекле формада).

8. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен Үзәк Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

9. Министрлык:

Үзәкнең заявкасын ул килгән көнне документ әйләнеше кагыйдәләре нигезендә терки;

заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Үзәк тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган документларны, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Үзәккә кире кайтара.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

Үзәкнең әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

Үзәк тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Үзәк тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

11. Субсидия күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

12. Субсидия бирү Министрлык һәм Үзәк арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә.

13. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидияне күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары;

Үзәк тарафыннан өстәмә хисап тапшыру срокларын һәм формаларын билгеләү өчен Министрлыкның хокукы;

агымдагы финанс елында Үзәк тарафыннан субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары;

Үзәкнең, Үзәк белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

моңа кадәр җиткерелгән, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә биреп булмауга китерә торган дәрәҗәдә киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт;

Үзәк тарафыннан әлеге Тәртипнең һәм төзелә торган килешүнең шартларын үтәү турында нигезләмәләр.

14. Үзәк кушылу, кушу яки үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Үзәкне бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук Үзәк бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә

булдырып һәм, Үзәк тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

15. Үзәккә, шулай ук Үзәк белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән тыш) сатып алу тыела.

16. Субсидия бирү нәтиҗәсе – Үзәкнең Иҗтимагый советының килешүдә билгеләнгән срокларда кимендә өч утырышын уздыру.

17. Субсидия Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Үзәкнең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерелә.

18. Үзәк квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән хисапларны әлеге хисаплар бирелгән көннән 10 эш көненнән артмаган срокта тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Министрлык Үзәкнең субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерә.

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәгә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

20. Бирелгән субсидия, әлеге Тәртиптә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия бирү шартлары Үзәк тарафыннан бозылган очракта, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

21. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, килешүдә каралган очракларда, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемөнә кире кайтарылырга тиеш.

22. Үзәк тарафыннан әлеге Тәртипнең 20 һәм 21 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.